ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 9 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1– 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яисә гражданнарга – өч мең сумнан алып дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – егерме биш мең сумнан алып кырык мең сумга кадәр; юридик затларга йөз мең сумнан алып ике йөз илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

б) 2 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – дүрт мең сумнан алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – кырык мең сумнан алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга биш йөз мең сумнан алып бер миллион сумга кадәр административ штраф салына.»;

в) 3 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – өч мең биш йөз сумнан алып дүрт мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз биш мең сумнан алып кырык биш мең сумга кадәр; юридик затларга өч йөз мең сумнан алып дүрт йөз илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

г) 4 өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – дүрт мең биш йөз сумнан алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – кырык биш мең сумнан алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга алты йөз мең сумнан алып бер миллион сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

2) 3.16 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.16 статья. **Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибен бозу**»;

б) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт чарасын түләүле муниципаль парковкага (парковка урынына) урнаштырган өчен түләмәүдә, йә муниципаль хокукый актта билгеләнгән күләмнән кимрәк түләү кертүдә, йә парковкадан файдаланган өчен муниципаль хокукый актта билгеләнгән түләү срогыннан соңрак түләү кертүдә чагылган түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалануның муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртибен бозган өчен –».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 25 октябрь
№ 86-ТРЗ